**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЮТАЗИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АБСАЛЯМОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
423957, с.Абсалямово
ул. Молодежная,2
E-mail: Absal.Utz@tatar.ru
тел./факс: 4-26-79

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ**
423957, Әбсәләм авылы
Яшләр урамы,2
E-mail: Absal.Utz@tatar.ru
тел./факс: 4-26-79

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№3**

**КАРАР
22 гыйнвар 2021 ел**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

2003 елның 6 октябрендәге Россия Федерациясе Бюджет кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында”гы 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы,Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Әбсәләм авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы һәм аны гамәлгә ашыру максатларында 2020 елның 21 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге торак пунктында гражданнар җыенының 1 санлы карары,

2020 елның 21 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге торак пунктында гражданнар җыенының 1 санлы карары;

2020 елның 25 декабрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсе торак пунктында гражданнар җыенының 3 санлы карары;

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын җыю тәртибен расларга

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, http://pravo.tatarstan.ruhttp://jutaza.tatarstan.ruмуниципаль районның рәсми сайтында Интернет мәгълүмати - телекоммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырылган: http://jutaza.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В. Кубашева

2021 елның 22 гыйнварындагы Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитетының
Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым җыю тәртибе турындагы 3 санлы карарына 1 кушымта

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Әбсәләм авыл җирлегендә**
**гражданнардан үзара салым җыю тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен әлеге тәртип билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчасы 2021 елның 22 гыйнварыннан 2021 елның 28 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган гражданнар, гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә башкарыла.

3. Билгеле сәбәпләр аркасында түли алмау түбәндәге очракларда карала:

а) яшәү урыны буенча озак вакыт яшәмәгән,

б) авыру булган

булган гражданнарга гариза язу нигезендә өч айга кадәр кичектерү каралырга мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында белдерү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук имзаны тапшыру яисә почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Белдерүдә (хәбәрнамәдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитетының шәхси счетына керә.

6. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша почта күчермәләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру юлы белән башкарыла.

7. Түләү фактын раслый торган касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

2021 елның 22 гыйнварындагы
Әбсәләм авыл җирлеге башкарма
комитетының 3 санлы
карарына 2 кушымта

Әбсәләм авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
БЕЛДЕРҮ (ХӘБӘРНАМӘ) №_____

Түләүченең Ф.И.А.
________________________________________________________________
Адресы:
________________________________________________________________
________________________________________________________________нигезендә
_______________________вакытка кадәр җыен чараларын тормышка ашыру өчен елга бер тапкыр түләүне _____________________________________ түбәндәге реквизитлар буенча түләүне тормышка ашырырга
киңәш итеилә:
Түләүне алучы банк ____________________________________
БИК _________________________________

Түләүне алучы ____________________________________________
Сч. № ______________________________________________
ИНН____________________КПП __________________
КБК ____________________ ОКАТО ______________
Билгеләнгән түләү
Гражданнарның үзара салым акчасы

Җитәкче_____________ _______________________________________
М.У. (имза) (имзаны раслау)

---------------- **кисү урыны** --------------

Әбсәләм авыл җирлеге бюджетына (муниципаль берәмлек исеме)
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турындагы_______________ *сумлык*
_______________ санлы белдерү (хәбәрнамә)
Түләүченең Ф.И.А.________________________________________________
Адрес:
________________________________________________________________
__
Алдым "___"___________20____ел ______________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Әгәр белдерү (хәбәрнамә) түләүчегә шәхсән тапшырылса, өзеп алынган өземтә Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тутырыла һәм аларда кала (саклана).*